# БЕЛДЕРҮ

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасы һәм 39.18 статьясы нигезендә һәм «2022 елда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 09.04.2022 номерлы карарын исәпкә алып, Кукмара муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «2022 елда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» күрсәтмәсен исәпкә алып, түбәндәге характеристикалары белән 20 елга җир кишәрлеген арендага бирү турында хәбәр итә:

Кадастр номеры 16:23:030102:143, мәйданы 2648 кв.м. булган җир категориясе: «Торак пунктлар җирләре», файдалану төре: «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» (күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләргә карагандa), кишәрлекнең урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Починок - Кучук авыл җирлеге, Починок - Кучук авыл җирлеге, Озерная ур., 14.

Югарыда күрсәтелгән җир кишәрлеген арендага алу белән кызыксынган гражданнар әлеге хәбәр басылып чыккан көннән алып 10 календарь көн эчендә аукционда язма рәвештә катнашырга ниятләү турында гариза (алга таба - гаризалар) бирергә хокуклы. Гариза мөрәҗәгать итүче (ышанычлы зат) эш көннәрендә (дүшәмбе-җомга, эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән тыш, ял көннәре дип игълан ителгән көннәрдән тыш) 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр, төшке ашка тәнәфес белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 15 йорт, 101 бүлмә.

Гаризалар кабул итү тәмамлану датасы - 15 сәгать 00 05.05.2022.